КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 28 декабрь г.Казань № 1237

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балалар ризыгын җитештерү өчен сөт китерүче авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә алынмый калган керемнәрен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2017 ел, 30 ноябрь, 929 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Балалар ризыгын җитештерү өчен сөт китерүче авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә алынмый калган керемнәрен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2017 ел, 30 ноябрь, 929 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 ел, 25 август, 740 нчы; 2021 ел, 29 май, 389 нчы; 2022 ел, 22 август, 874 нче; 2023 ел, 20 гыйнвар, 26 нчы; 2024 ел, 16 декабрь, 1143 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Бюджет кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Юридик затларга, индивидуаль эшкуарларга, шулай ук товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүче физик затларга Россия Федерациясе субъектлары бюджетларыннан, җирле бюджетлардан субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантлар бирүне һәм әлеге субсидияләрне, шул исәптән субсидияләр рәвешендә грантларны алучыларны сайлап алуны үткәрүне җайга сала торган норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләрне раслау турында» 2023 елның 25 октябрендәге 1782 номерлы карары, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының

«Татарстан Республикасында гражданнарга социаль ярдәм күрсәтү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 23 декабрь, 1023 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасында гражданнарга социаль ярдәм күрсәтү» Татарстан Республикасы дәүләт программасы, өч яшькә кадәрге балаларны махсус сөт продуктлары белән тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

әлеге карар белән расланган Балалар ризыгын җитештерү өчен сөт китерүче авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә алынмый калган керемнәрен каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

2. Әлеге карар 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин